Казан (Идел буе) федераль университеты
Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбе



# Рауштан

Студентлар газетасы

№24/29.03.2017

## МОГҖИЗА – БЕЗ ҮЗЕБЕЗ!

Яз житү белән, урамда ташу аккан сыман, студентлар да активлаша, каядыр чаба, ашыга башлыйлар. Әйе, алар ел да көтеп ала торган «Студентлар язы»на әзерләнә. Быел да әзерлек берничә атна алдан башланды. Билетлар да мизгел эчендә таралып бетте. Моның сәбәбе дә билгеле – ИФМКның «Студентлар язы»ндагы чыгышлары бөтен залны үзенә җәлеп итә.

16 март Уникс концертлар залында «Студентлар язы – 2017» фестиваленең чираттагы сайлап алу көне булды. Яшь талантлар үзләренең яңа чыгышлары белән жюри әгъзаларын таң калдырырга тырыштылар. Бу көнне Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты белән Экология һәм табигатьне файдалану институты студентлары көч сынаштылар.





Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты бу фестивальгә зур җаваплылык белән карый һәм ел да иң шәп чыгыш ясаучылар рәтендә санала. Быел да институтыбыз үзенең талантлы студентлары белән югары дәрәҗәдәге осталык күрсәтте. Тамашачыларның алкышлавына карасак, Илья Захаров, Юлия Соловьева, Наталья Ярославцева, «High school grind» вокал-инструменталь ансамбле һәм “Яшьлек” бию коллективы чыгышлары аеруча кызыксыну уятты. “Юан фэн” төркеменең кытай телендә “Mei li de shen hua” җырын башкаруы да Корея сериалларын яратучы нәфис кызларыбызның күңеленә хуш килгәндер.

Илназ Сибгатуллин һәм “Яшьлек” бию ансамбле безне үткәннәргә, Болгар чорына алып кайттылар, күзләребезгә яшь кунды, йөрәкләргә горурлык хисе тулды.

Аеруча җанатарлар төркемен мактап үтәсе килә. Алар һәр чыгышка төрле хәрәкәтләр ясап, залны җанландырып, аерым бер атмосфера барлыкка китереп тордылар.

Җыр-биюләрдә катнашучылар студент тормышының төп кыенлыкларын һәм татлы мизгелләрен күрсәтергә тырыштылар. Әти-әнигә, яраткан кешеңә вакыт җитмәү, сессия, шулай ук матур гаилә кору турында хыяллар чагылды сәхнәдә.

Үз бурычларыңны төгәл үтәргә, үз хыялларыңа таба атларга һәм могҗиза барлыгына ышанырга кирәк. Могҗиза?! Тукта! Могҗизалар булмый ул... Могҗиза – без үзебез!

**Алмаз Шиһабетдинов, 2 курс студенты**

## БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...

Безнең уку йортында бик күп төрле чаралар уза. Аларда катнашып була, аларны оештырып була. Биисең килсә, биисең; җыр ярατсаң, җырлыйсың; иҗатчы булсаң, шигырьләр язасың...

Институтыбызда төрле проектлар эшләнелә. Алар төрле максат белән барлыкка килергә мөмкин, төрле аудиториягә карарга, үзенең юнәлешен алырга мөмкин. Инде менә бер елдан артык шул проектларның берсе бик яхшы гына эшләп килә. Ул да булса, “SpellBattle” исемле орфографик уен. Аның турында күп кенә студент белә, бу проектның үз аудиториясе, географиясе һәм урыны бар. “SpellBattle” үзе дә төрле конкурсларда катнаша, үзен яхшы яктан күрсәтә, катнашучыларны күп нәрсәгә өйрәтә.



Мин бу проект турында беренче курста укыганда ишеттем. Икенче курс алдыннан җәй көне социаль челтәрдә шундыйрак мәгълүмат күрдем: «“SpellBattle” проекты үзенә оештыручылар төркеме җыя. Теләүчеләр булса, Гүзәл Шәвәлиевага (3 нче курс студенты, бу проектны оештыручы) языгыз!»

Мин моны үземә бик кызыклы итеп күрдем дә, шул ук көнне Гүзәлгә яздым. Һәм шуннан башланып китте... Миңа оештыручылар төркемендә булу бик күп яңа тәҗрибә бирде, күп кенә әйберләргә өйрәндем.

Нинди соң ул безнең проект? Бу – уен, аның үз кагыйдәләре бар. Кыскасы: уенда катнашучылар төрле телдәге сүзләрне алфавит авазлары белән әйтеп чыгарга тиешләр. Уеныбызда кыңгырау бар. Катнашучылар парларга бүленеп чыгалар. Жюри әгъзалары сүзне әйтә; кем беренче, шул кыңгырауга баса һәм сүзне әйтә булып чыга. Дөрес әйтмәсә, икенче кешегә мөмкинлек бирелә. Уенда җиңүчегә кызыклы бүләк һәм диплом бирелә. Бар катнашучы да сертификат ала. Күбрәк мәгълүмат аласыгыз килсә, “ВКонтакте”дагы төркемгә кереп, бездән сорап белә аласыз. Алда безне Лига көтә, уеннарда сезне дә көтеп калабыз!



**Регина Газизҗанова, 2 курс студенты**

# ТУЛАЙ ТОРАКТА ТОРМАГАН - СТУДЕНТ БУЛМАГАН!





Бу сүзләрне һәрберебезнең ишеткәне булгандыр. Тулай торак студент тормышында бик зур роль уйный. Авыр уку көненнән соң анда сине нинди күңелле һәм кызык хәлләр көтүен истә тотып кайтып керәсең. Дусларың белән кич бергәләп утырып уеннар уйныйсың, бер-береңнән көләсең, ашарга пешерү чираты турында бәхәсләшәсең. Ни генә булса да, тулай торак ул студентны мөстәкыйль булырга өйрәтә. Монда аш пешереп торырга, иртә белән сине уятырга әни кеше юк, барысын да үзеңә эшләргә кирәк.

Шунысы да бар: әгәр тулай торакта үз-үзеңне тиешле дәрәҗәдә тота белмисең икән, сине монда яшәүчеләр яхшы кабул итмәячәкләр. Монда торуның борынгыдан килгән бер кагыйдәсе бар: ул − аралаша, күңел ача белү. Һәм сүз спиртлы эчемлекләр куллану турында бармый. Әгәр башкалардан аерылып, бүлмәңдә генә утырасың икән, сиңа кырын күз белән карап китәчәкләр. Җор күңелле булырга кирәк, андый кешеләрне бөтен җирдә яраталар, үзеңә дуслар табарга да күпкә җиңелрәк булачак.

Иң рәхәте − бүлмәдә берничә кеше белән тору, алар синең белән бер төркемдә укысалар, тагы да шәбрәк. Сез бергәләп өй эше эшли аласыз, имтиханнарыгыз да бер үк вакытта бетәчәк, берәр концертка, клубка баруны планлаштыру да авырлык китермәячәк. Бергәләп кибеткә барып, азык-төлек алып, аш пешерергә була. Аш пешерү ул − үзенә бер аерым вакыйга. Студент, гадәттә, күп ризык пешерә дә белми: пилмән, бәрәңге, тәбә – боларны еллар буе ашарга була. Әгәр башка кеше пешерә алмаган ризыкны пешерсәң, синең этажда яшәүчеләр аның исен сизеп, шунда ук кухняга килеп җитәчәк. Синең инде башка юлың калмый, аларны да ашатасың була. Әгәр синдә «повар сәләте» булса, тулай торакта тәгаен дусларсыз калмаячаксың.

Иң мөһиме, холкы синекенә туры килгән күршеләрне сайлый белү. Әгәр син укуга бирелгән кеше икән, күршең дә шундый булса, бик әйбәт. Юкса укыган чагында ул сиңа комачауласа, арагызда конфликт килеп чыгачак һәм уку беткәнчегә кадәр бер-берегез белән сөйләшмичә йөриячәксез. Бер бүлмәдә торып, бер-береңә кырын карап узу матур күренеш түгел, шуңа күрә бу очракта күршең белән утырып сөйләшергә, компромисс табарга тырышырга кирәк. Дустымның тормышында шундый хәл булды: ул бүлмәдә дүрт кеше белән торды, дүртесе дә музыка кычкыртып бәйрәм итәргә, тавыш чыгарырга ярата торганнардан иделәр, ә дустым андый әйберләр белән кызыксынмый, тынычлык ярата. Шуннан дустым түзә алмагач, үзләре белән утырып сөйләште, бүлмәдәшләре аны аңлады һәм алар бер-берсенә юл куеп, тату гына яши башладылар.

«Тулай торакта тормаган – студент булмаган», − диләр. Ә сезнең тулай торакта кызык хәлләргә юлыкканыгыз бармы?

**Рүзәл Мөхәммәдиев, 2 курс студенты**

### *ТУКАЙГА ХИТАБ*

*И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!*
*Шигъри аһәң, илһам биргән, кабатланмас син, Казан!*

*Тукай абый, җаны тартып, нәкъ сиңа килгән, калам,*
*Сине күреп, ул әйткәндер: китмим мин, монда калам!*

*Тарихлар, тәкъдир сынады, шөкер! түздек, башкала,*
*Ачысын һаман татыйбыз, башларыбыз айкала...*

*Таксист-кучер, ку атыңны, текә номер — биш-биш-биш,*
*Җан эзләгән оҗмахларың шул булырмы, әй, дәрвиш?*

*Юк, гасырлар алмашынды, пар ат калды үткәндә.*
*Апуштан Тукай булырга теләгән яшьләр килә!*

*Иһ, тарсынма! Бул иректе! Ташкалам, эндәш миңа!*
*Халкым тав(ы)шы "ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна"...*

***Амур кызы***

### *ОЗАТУ*

*Кайдадыр шаулаган җил көче*
*Минем йөрәгемә шом сала.*
*Күптәнге танышым булсаң да,*
*Беренче күргәндәй оялам.*
*Сүзләре таралды сәйләндәй –*
*Кем җыяр,*
*Кем моны булдырыр?*
*Күңелдән-күңелгә салават күпере,*
*Койма яны. Өйләр. Ялан кыр.*
*Кайдадыр шаулый торган җил*
*Маңгай сырларыңны арттырыр.*
*Чигеп бизәлгән кулъяулыкны*
*Саклап кына сиңа тоттырам.*
*Бер ел озак түгел. Меңләгән*
*"Сагынам",*
*"Көтәм",*
*"Кайт инде".*
*Истәлегем, вәгъдәм, антым булып*
*Кулъяулыгым йөрәгеңә иңде.*

***Алсу Салахова***

### ***

*Икейөзле дөнья ике йөзен чөергәндә,*
*ике каршы – бәхет белән хәсрәт сиңа дәшмәс чакта.*
*мөлдерәмә тулы күңлең бушап калып,*
*әллә нинди гөнаһ уйлар күңлең чакса,*

*тынгысыз бул!*
*күтәреп чөй күзләрдәге хәлсезлекне,*
*мең кисәккә ерткалап ат буш уйларны.*
*эзлә, кычкыр, ела, кыйна, карыш берүк!*
*Син бит әле бу тормыштан һич туймадың!*

*Туймадың бит?!*
*мин ышанам: яшәү һәм син*
*әле тиеш берсен-берсе хак сөяргә!*
*коч бу таңны, бу төн утын, болытларны!*
*Өметең коч! Тик бушлыкка син сөялмә.*

*сөял кышка, салкын буранына. Алар сиңа*
*күзең йомып егылырга ирек бирмәс!*
*Син беләсең: җылы, уңай чакта,*
*Башың салып сүнеп калу күпкә рәхәт...*

*Тик син сүнмә!*
*Йөгер кышка! Бураннарын*
*Йотып-йотып күңелеңә сеңдер бары!*
*Алар сине сүндермәсләр, әле озак*
*күңелендә кайтавазы тузгып торыр.*

*син беләсең: күңел тулы бушлык,*
*кайгы тоташ көннәрдән дә күпкә кыен.*
*ирек бирмә бу бушлыкка коенырга*
*хәятыңда синең,*
*Чал кышларга сыен!*

***Гүзәл Закирова***

## ТАБЫШМАК



Барыбызны дус итә,
Диалектларны әйбәт белә
Дәрестә шаяру ярый
Ул безнең ...

vk.com/rawshan_ifmk
@NEWRAUSHAN
NewRaushan@gmail.com

Баш мөхәррир – Халисә Ширмән Мөхәррир - Дамир Хөснетдинов
Иҗат коллективы:Айгөл Шәйдуллина, Чулпан Фатыхова, Алмаз Шиһабетдинов, Регина Газизҗанова, Рүзәл Мөхәммәдиев.
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Чулпан Фатыхова
Редакциянең фикере авторларның фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Газетаны гамәлгә куючы Казан (Идел буе) федераль университеты
Л. Толстой ис. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының
Г. Тукай ис. тюркология һәм татаристика югары мәктәбе
Редакция адресы: 420021, Татарстан ур., 2 , 127 бүлмә. Хәбәрләшү өчен телефон: 89274019142 Электрон почта: raushantat@yandex.ru